| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 12.08.2020 | Зур Тигәнәле авылы | № 155 |

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»**
**2018 елның 16 ноябрендәге 104 номерлы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 407 маддәсендәге 6 пунктына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Алексеевск районы прокуратурасының 2020 елның 14 июлендәге 02-08-03 номерлы протестын үтәү йөзеннән

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 16 ноябрендәге 104 номерлы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

4 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым ташламасына хокукы булган физик зат салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза бирә, шулай ук әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән, аның салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы».

2. Әлеге карар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет челтәрендә рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы 17 йорт; “Әшнәк” кибете бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Әшнәк авылы, Х.Вахит урамы, 11 йорт махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**